**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________________ ПР-131 03.06.2025 №______

«Сабантуй — 2025» татар халык бәйрәмен уздыру турында

Татарстан Республикасы Рәисенең «Сабантуй» татар халык бәйрәмен уздыру турында» 2025 елның 17 мартындагы 204 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Башлыгының « Районда «Сабантуй» татар халык бәйрәмен уздыру турында» 2025 елның 28 маендагы ПГ-19 номерлы карары нигезендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Сабантуй - 2025» татар халык бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү буенча район комиссиясе составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.;

2. Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына:

2.1. бәйрәм уздырыла торган урыннарда сәүдә нокталарының дислокациясен билгеләргә, аларның эшен тәэмин итәргә;

2.2. районның төп магистральләрендә, шулай ук бәйрәм уздырыла торган урыннарда урнашкан сәүдә һәм кулланучылар хезмәтләре күрсәтү объектларын сәнгати һәм тематик яктан бизәү эшләрен оештырырга, әлеге объектларның җитәкчеләренә үзләренең сәүдә нокталары янына каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар куярга һәм бәйрәм тәмамланганнан соң җыештыруны тәэмин итәргә киңәш итәргә;

3. Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын уздыруны, мәйданны сәнгатьчә бизәүне тәэмин итәргә.

4. Икътисад буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына, финанс-бюджет палатасы рәисенә тапшырылган счетлар өчен түләүне расланган смета нигезендә башкарырга.

5. Тәкъдим итәргә:

5.1. «Коммунсервис» МУП директорына мәйданда һәм аның тирәсендәге территорияләрдә бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын төзекләндерергә;

5.2. Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары район Советы һәм Башкарма комитетының тармак бүлекчәләре, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре белән берлектә районны һәм бәйрәмне үткәрү урыннарын бәйрәмчә бизәү эшләрен шәхсән үз контрольләренә алырга;

5.3. Районның үзәк магистральләрендә урнашкан сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре һәм башка оешмалар җитәкчеләренә фасадларны, вывескаларны, витриналарны бизәргә, рекламаның яктылык режимын, объектларның эчке интерьерларын төзекләндерү кагыйдәләре таләпләренә туры китерергә;

5.4. Оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына карамастан, район предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә бәйрәм чараларын финанслауда өлешчә катнашырга;

«Сабантуй-2025» татар халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда катнашырга, эшләрне план нигезендә башкаруны оештырырга;

5.5. Актаныш янгын-коткару гарнизоны башлыгына бәйрәм урыннарында янгынга каршы чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

5.6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгына җәмәгать тәртибен саклауны, мәйдан янындагы чатыр формаларын, йорт, конструкцияләрне саклауны, татар халык бәйрәме «Сабантуй-2025» уздырган вакытта монтаж һәм демонтаж чорына бәйрәм бизәлешен саклауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш. Бариев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына «___»_______2025 ел
1 нче кушымта

«Сабантуй-2025» татар халык бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү буенча район комиссиясе составы*

И.Ш.Бариев - комиссия рәисе, Башкарма комитет җитәкчесе;

И.И. Габдулхаев- комиссия рәисе урынбасары, район Башлыгы урынбасары;

М.З.Гыйлаева- Актаныш муниципаль район Советының оештыру бүлеге башлыгы, комиссия секретаре;

Н.Ә.Сәлимгәрәев- Актаныш районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);

Л.Р.Сираева - Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;

И.Р.Вахитов - муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе;

Д.М.Әнвәрова - Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

А.А.Корбангалина - финанс-бюджет палатасы рәисе;

Р. И. Мулюкова - икътисад бүлеге башлыгы;

Р.М.Шакирова - «Мәгариф идарәсе»МКУ башлыгы;

Н.Ф.Исламова - социаль һәм агарту бүлеге башлыгы;

А.Х.Магданов - яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;

Р. Р. Шәрипов - "Коммунсервис" МУП директоры;

К.Н. Әхмәдгалиев - Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

М.Р.Минһаҗев - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлек башлыгы;

Л. М. Хафизова- Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Чаллы шәһәрендә бүлек башлыгы урынбасары;

Д.М.Нәгыймов - "Теплосервис" ҖЧҖ директоры;

И.М.Мортазин - 103 нче янгын сүндерү-коткару бүлеге башлыгы;

А.Р. Хәев - "Актаныш район үзәк хастаханәсе" ДАССУ баш табибы;

Ф.Ә. Абдрахманов - Актаныш дәүләт ветеринария берләшмәсенең баш табибы;
*комиссиянең Башкарма комитет җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган әгъзалары килештерү буенча комиссия составына кертеләләр.